**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXIII СЕССИЯСЕ**

**К А Р А Р № 135**

Мөслим авылы «14» декабрь 2022 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы «Мәллә-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен раслау турында**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мәллә-Тамак авыл җирлеге территориясен тотрыклы үстерү, әйләнә-тирә мохитне саклау өчен шартлар тудыру, физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен планлаштыру, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 статьясындагы 1 пунктына, 30,32 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мәллә-Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Уставында билгеләнгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Мөслим муниципаль районының веб-адрес буенча рәсми сайтында http://muslumovo.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенчаТатарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә дип билгеләргә.

Мөслим муниципаль районы Башлыгы,
Мөслим муниципаль районы Советы рәисе А.Р.Хуҗин